Кукмара муниципаль районы
**Чарлы** авыл Башкарма комитеты

КАРАР

« 31» январь 2025 ел № 2

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2024 елның 30 гыйнварындагы 6 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында» Кукмара муниципаль районы Советының 2024 елның 2 августындагы 261 номерлы карары, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2025 елның 30 гыйнварындагы 82 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге Башкарма кометитынын 2024 елның **30** гыйнварындагы **6** номерлы карарын 2025 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче Э.Н.Козлов

ОГРН 1061675010946
ИНН 1623008440